**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**13.09.2018** **№ 1998**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 12 февралендәге 371 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарына гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 26 маендагы 147 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 12 февралендәге 371 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 6.9.1. пункт белән тулыландырырга:

«6.9.1. Миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу мөмкин булган фактлар турында мәгълүматны үз эченә алган язма мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып биш көн эчендә, әлеге Нигезләмәнең 5 пунктындагы 5.8, 5.9 пунктчаларында күрсәтелгән очрактан тыш, мөрәҗәгать юллаган гражданга аның мөрәҗәгатен яңадан адреслау турында хәбәр итеп, хокук куллану функцияләрен, миграция өлкәсендә контрольлек, күзәтчелек һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органының территориаль органына һәм Татарстан Республикасының югары вазыйфаи затына (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) җибәрелә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин